КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 302

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру советы составына үзгәрешләр кертү хакында

Кадрлар үзгәрүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру буенча алга таба чаралар турында» 2008 ел, 27 июнь, 451 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 сентябрь, 639 нчы; 2017 ел, 8 июнь, 364 нче; 2018 ел, 16 май, 372 нче, 2021 ел, 25 март, 168 нче, 2022 ел, 19 апрель, 368 нче, 2022 ел, 6 декабрь, 1295 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының телләр турындагы законнарын тормышка ашыру советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Совет составыннан Т.Д.Сөләймановны чыгарырга;

Совет составына Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министры Садыйков Ринат Наил улын кертергә;

Сәфәров Әсгать Әхмәт улы вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, Совет рәисе урынбасары (килешү буенча)»;

Мөхәрләмов Руслан Роберт улы вазыйфасы  исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин